# ГАЛӘМ

*7 сыйныф*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ЮЛСУБИНО ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

**№8**

*24.10.22-28.10.22*




25 нче октябрьдә Алексеевск районының Базарлы Матак авылында 2009-2011 нче елгы егетләр һәм кызлар арасында билбау көрәше буенча ярышлар булып узды. Әлеге бәйгедә безнең мәктәптән 7 нче сыйныф укучысы Зиятдинов Инсаф районыбыз данын яклап катнашты һәм 44 килограмм авырлык категориясендә 3 нче урынны яулады. Безнекеләр сынатмыйлар!

28 нче октябрьдә, 1 нче чирекне йомгаклаганнан соң, мәктәбебездә “Көзге бал” бәйрәме үткәрелде. Бу көнне еллык хезмәткә йомгак ясалды. Һәр сыйныф укучысы актив катнашты, бәйрәм уен һәм җырлардан гөрләп торды. Башлангыч сыйныф укучылары башкаруындагы “Яфрак коелу” , югары сыйныф укучыларының “Көзге вальс” биюләре бәйрәмнең кульминацион ноктасына туры килгәндер, мөгаен.



